ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№203 от «19» 03 2023 г.

Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 10 гыйнварындагы 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 10 гыйнварындагы «Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 1 нче номерлы карарына карата Мамадыш районы прокуратурасының 2023 елның 15 маендагы N02-08-02 протесты нигезендә, Норматив хокукый актларны Россия Федерациясе Торак кодексына, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бинаны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану хакында» 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 10 гыйнварындагы «Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 1 нче номерлы карарына (алга таба- Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 2.4.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтелә:

18 эш көне дәвамында, гариза биргән көнне дә кертеп, бинаны тикшермичә;

урынны карау акты төзелгән очракта, 22 эш көне дәвамында (4 нче Кушымта).».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгагрырга һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка

0000011782

җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.М.Никифоровка йөкләргә.

Җитәкче О.Н.Павлов